РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Исполнительный комитет
Масягутовского сельского
поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Дружба, д. 12, Азнакаевский
район, с.Масягутово, 423321,
тел./факс (885592)38-2-16
E-mail: Msg.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Мәсгут авыл җирлеге
башкарма комитеты

Дружба ур., 12 йорт, Азнакай
районы, Мәсгут авылы, 423321
тел./факс (885592)38-2-16
E-mail: Msg.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«10» декабрь 2024ел.** **№ 11**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 16 ноябрендәге 22 номерлы «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге территориясендә террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау буенча муниципаль программа турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 мартындагы 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Экстремистик эшчәнлеккә каршы тору турында» 2002 елның 25 июлендәге 114-ФЗ номерлы, «Террорчылыкка каршы тору турында» 2006 елның 06 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 16 ноябрендәге 22 номерлы «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәсгут авыл җирлеге территориясендә террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау буенча муниципаль программа турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Исемендә һәм 1 пунктта «2023-2025 елларга» сүзләрен «2023-2027 елларга»сүзләренә алмаштырырга.

1.2. Кушымтаны әлеге карарга кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Башкарма комитетына ел саен чираттагы финанс елына авыл җирлеге бюджеты проектын формалаштырганда 2025-2027 елларга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге территориясендә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау буенча муниципаль программа чараларын финанслауны күздә тотарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз естемдә калдырам.

Башлык И.А.Вильданов

Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына кушымта
10.12.2024 ел. №11

2023-2027 елларга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсәгут авыл җирлеге территориясендә террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау буенча муниципаль программа

## 1. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге Программа «Экстремистик эшчәнлеккә каршы тору турында» 2002 елның 25 июлендәге 114-ФЗ номерлы Федераль закон, «Террорчылыкка каршы тору турында» 2006 елның 06 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләне гамәлгә ашыру кысаларында - террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалауда, шулай ук минимальләштерүдә һәм (яисә) бетерүдә катнашу Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге территориясендә террорчылык һәм экстремизм чагылышлары нәтиҗәләрен минимальләштерүдә һәм (яисә) бетерүдә максатларында эшләнгән.

## 2. Муниципаль программаның агымдагы торышына һәм максатына характеристика

Террорчылык һәм экстремизм хәзерге шартларда террорчылык һөҗүмнәренең потенциаль объектларының иҗтимагый тотрыклылыгы, тынычлыгы һәм сакланышы өчен җитди куркыныч булды. 2018 елда Татарстан Республикасы территориясендә дини биналарга ут төртү очраклары булган. Исламның традицион булмаган формалары таралу фактлары бар.

Теп проблемалар булып:

-террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалауда катнашуны финанс белән тәэмин итүнең булмавы;

-авыл җирлеге халкы белән террорчылык һәм экстремистлык эшчәнлеген кисәтүгә юнәлдерелгән пропаганда һәм тәрбия эшләрен җитәрлек дәрәҗәдә үткәрмәү;

-заманча саклау һәм янгын сигнализациясе чаралары, куркынычсызлык һәм үтеп керүне контрольдә тоту системалары белән җиһазландырылган объектларның, учреждениеләрнең җитәрлек дәрәҗәдә җиһазландырылмавы;

-матди-техник базаны яхшырту дәрәҗәсе түбән булуы тора.

Матди зыянны киметү, террорчылык һәм экстремизм чагылышларын киметү һәм (яисә) зыянны бетерү максатында бу эштә муниципаль программа этәргеч булып тора.

Программаның максаты-авыл җирлеге халкын террорчылык куркынычыннан яклау, террорчылык һәм экстремистлык эшчәнлеген вакытында кисәтү, ачыклау һәм туктату.

Бу максатка ирешү өчен кайбер теп бурычларны хәл итәргә кирәк:

- авыл җирлегендә яшәүчеләрне террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалауда, шулай ук аларның нәтиҗәләрен минимальләштерүдә һәм (яисә) бетерүдә катнашуга җәлеп итү;

җинаятьчел һөҗүмнәрнең потенциаль максатлары сыйфатында террорчылар тарафыннан сайланырга мөмкин булган объектларны, учреждениеләрне һәм кешеләр күпләп була торган урыннарны яклау;

- террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау, аларның чагылышына китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны бетерү буенча тәкъдимнәр әзерләү һәм чаралар эшләү.

- хокук саклау органнары, мәдәният учреждениеләре, мәгариф учреждениеләре белән хезмәттәшлек итү.

### 3. 2023-2027 елларга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге территориясендә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау буенча муниципаль программа паспорты

| | |
|---|---|
| Муниципаль программа исеме | 2023-2027 елларга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге территориясендә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау буенча муниципаль программа |
| Программаны эшләү нигезләре | «Террорчылыкка каршы тору турында» 2006 елның 06 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон,<br>«Экстремистик эшчәнлеккә каршы тору турында» 2002 елның 25 июлендәге 114-ФЗ номерлы Федераль закон,<br>«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон,<br>Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге башкарма комитетына җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты вәкаләтләренең бер елешен тапшыру турында 09.01.2018 елгы килешү |
| Программаның максатлары һәм бурычлары | Программаның максаты:<br>- террорчылыкка һәм экстремизмга каршы тору, муниципаль берәмлек территориясендә яшәүче гражданнарның гомерен террорчылык актларыннан һәм экстремистик чагылышлардан яклау;<br>- башка милләт һәм дини конфессияләрнең экстремизм чагылышларын һәм аларга карата тискәре менәсәбәтне киметү;<br>- күпмилләтле Россия җәмгыяте кыйммәтләре, мәдәни үзаң, кеше хокукларын һәм ирекләрен саклау принциплары нигезендә башка милләт һәм дини конфессия кешеләренә карата эчке толерант тотышка ихтыяҗ тудыру;<br>яшьләр арасында толерантлык һәм милләтара мәдәният формалаштыру, агрессив тәртип профилактикасы.<br>Программаның бурычлары:<br>- милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгыту, социаль, этник һәм конфессиядә конфликтларны профилактикалау һәм булдырмый калу;<br>- халыкның террорчылык күренешләренә каршы түзеп тора алмау атмосферасын булдыруга юнәлдерелгән җәмәгать фикерен формалаштыру |
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары | 2023 -2027 еллар |
| Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны финанслау чыганагы-Мәсгут авыл җирлеге бюджеты акчалары:<br>2023 елда-0,0 мең сум<br>2024 елда-0,0 мең сум<br>2025 елда-80,0 мең сум<br>2026 ел-100,0 мең сум |

| | |
|---|---|
| | 2027 ел-50,0 мең сум |
| Кетелә торган ахыргы нәтиҗәләр: | - Мәсгут авыл җирлеге территориясендә террорчылыкны һәм экстремизмны, ксенофобия, милли һәм раса түземсезлеген профилактикалау, этник дискриминациягә каршы тору буенча җирле үзидарә органнарының эш формаларын һәм ысулларын камилләштерү;<br>гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә учреждениеләр укучылары арасында интернационализм, татулык, милли һәм дини түземлелек культурасын тарату;<br>- милләтара менәсәбәтләрне гармонияләштерү, этносоциаль уңайлылык дәрәҗәсен күтәрү;<br>- Мәсгут авыл җирлеге территориясендә толерантлык, гражданнар теләктәшлеге, башка мәдәниятләргә хермәт идеяләрен пропагандалау ечен бердәм мәгълүмати пространство булдыру. |
| Программаның үтәлешен тикшереп тору | Программаның үтәлешен авыл җирлеге башлыгы тикшереп тора |

## 4. Программаны ресурслар белән тәэмин иту

4.1. Программа Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Мәсгут авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле бюджеты акчалары хисабына гамәлгә ашырыла.
4.2. Программаны җирле бюджет акчалары исәбеннән финанслау күләме ел саен Мәсгут авыл җирлеге Советының чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Мәсгут авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты турындагы карары белән билгеләнә торган финанслау күләмнәре нигезендә тегәлләштерелә.

**Программаның төп чаралары исемлеге, аларны гамәлгә ашыру сроклары һәм финанслау күләмнәре**

| № т/б | Чараның атамасы | Башкаручы | Гамәлгә ашыру вакыты | Финанслау чыганагы | Еллар буенча финанслау күләме | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2023 | 2024 | 2025 | 2026 | 2027 |
| 1. | Җирлек территориясендә террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау мәсьәләсе буенча учреждениеләрдә һәм оешмаларда гражданнар җыелышлары һәм чаралары үткәрү | Авыл җирлеге Башлыгы, Авыл җирлеге Башкарма комитеты | 2023-2027 еллар дәвамында | Финанслау таләп ителми | | | | | |
| 2. | Гражданнарның иминлеген, аларның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү, тормышны тәэмин итү объектларын, потенциаль куркыныч объектларны комплекслы тикшерүләр уздыру | Авыл җирлеге башкарма комитеты, ДНД | 2023-2027 еллар дәвамында | Финанслау таләп ителми | | | | | |
| 3. | Балаларны һәм яшүсмерләрне дини секталарның һәм экстремистик оешмаларның законсыз эшчәнлекләренә җәлеп итүгә юл куймауга юнәлдерелгән профилактик эшне оештыру. Милләтара (этникара) түземлелек, дуслык, татулык, үзара ихтирам идеяләрен тарату | Авыл җирлеге Башкарма комитеты, хокук саклау органнары (килешү буенча) | 2023-2027 еллар дәвамында | Финанслау таләп ителми | | | | | |
| 4. | Террорчылык актларын кисәтү һәм алар барлыкка килгәндә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре буенча авыл | Авыл җирлеге мәдәният йорты | Квартал саен | Финанслау таләп ителми | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | мәдәният йорты персоналы белән укыту тренировкалары үткәрү | хокук саклау органнары (килешү буенча) | | | | | | | |
| 5. | Мәдәният учреждениеләренең яшь кешеләр аңында шәхси һәм күмәк бурыч идеяләрен безнең җәмгыятьтә кеше хокукларын һәм терлелекне хөрмәт итү (кешеләр арасында мәдәни, этник, дини, сәяси һәм башка аерымлыклар чагылышы буларак) идеяләрен раслау буенча эшен оештыру | Авыл җирлеге мәдәният йорты (килешү буенча) | Айлап | Финанслау таләп ителми | | | | | |
| 6. | Вазыйфаи затлар һәм белгечләрне эшкә җәлеп итү, тәрбия һәм пропаганда чараларын гамәлгә ашыру | Авыл җирлеге Башкарма комитеты, Авыл җирлеге мәдәният йорты (килешү буенча) | 2023-2027 еллар дәвамында | Финанслау таләп ителми | | | | | |
| 7. | Буш йортларны һәм биналарны даими тикшерүләр оештыру, учреждениеләрне аларның террорчылыкка каршы якланганлыгын тикшерү максатларында комплексы тикшерүләр уздыру (тикшерүләр үткәрү, подвал биналарын ябу) | Авыл җирлеге Башкарма комитеты, хокук саклау органнары (килешү буенча), учреждениеләр һәм оешмалар җитәкчеләре (килешү буенча) | Айлап | Финанслау таләп ителми | | | | | |
| 8. | Террорчылык актлары барлыкка | Авыл җирлеге | Айлап | Финанслау таләп | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | килү куркынычы янаганда, мәгълүмат стендларында массакүләм булу урыннарында мәгълүмат стендларында мәгълүмат урнаштыру юлы белән авыл җирлеге халкына эш итү тәртибе турында хәбәр итәргә. | Башкарма комитеты | | ителми | | | | | |
| 9. | Авыл җирлеге территориясендә экстремистик характердагы мәгълүмат материалларын тарату фактларын ачыкларга. Әлеге фактлар турында хокук саклау органнары хәбәр итә. | Авыл җирлеге башкарма комитеты | 2023-2027 еллар дәвамында | Финанслау таләп ителми | | | | | |
| 10. | Гражданнарның, шул исәптән чит ил кешеләренең һәм гражданлыгы булмаган затларның авыл җирлеге территориясендә законсыз яшәү (булу), аларны хезмәт эшчәнлегенә законсыз җәлеп итү фактларын ачыклау, булдырмау. | Авыл җирлеге Башкарма комитеты, хокук саклау органнары (килешү буенча), РФ ФМС ТР буенча Азнакай бүлеге (килешү буенча) | Кендәге | Финанслау таләп ителми | | | | | |
| 11. | Җирлек территориясендә экстремизм һәм террорчылыкны профилактикалау буенча плакатлар, стендлар әзерләргә һәм урнаштырырга. | Авыл җирлеге Башкарма комитеты | 2023-2027 еллар дәвамында | Авыл җирлеге бюджеты | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 50,0 |
| 12. | ДНД әгъзалары катнашында массакүләм, мәдәни һәм спорт чаралары уздыруның террорчылыкка каршы якланганлыгын тәэмин итү | Авыл җирлеге Башкарма комитеты | 2023-2027 еллар дәвамында | Финанслау таләп ителми | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 13. | Яшьләрнең толерант аңы дәрәҗәсен күтәрүгә ярдәм итүче мәгълүмати материаллар китапханәсе укучылары арасында тарату | Авыл җирлеге Башкарма комитеты | 2023-2027 еллар дәвамында | Финанслау таләп ителми | | | | | |
| 14. | Авыл җирлеге хокук бозуларын профилактикалау советы утырышларын уздыруны, проблемалы мәсьәләләрне карауны тәэмин итү | Авыл җирлеге Башлыгы, Авыл җирлеге Башкарма комитеты | 2023-2027 еллар дәвамында | Финанслау таләп ителми | | | | | |
| 15. | Мәсгут авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында һәм Мәсгут авылы мәдәният йорты бинасында видеокүзәтү системасы хезмәт күрсәтү | Авыл җирлеге Башлыгы, Авыл җирлеге Башкарма комитеты | 2023-2027 еллар дәвамында | Авыл җирлеге бюджеты | 0,0 | 0,0 | 80,0 | 100,0 | 0,0 |
| **Барлыгы:** | | | | | 0,0 | 0,0 | 80,0 | 100,0 | 50,0 |
| **Шулардан, җирлек бюджеты акчалары:** | | | | | 0,0 | 0,0 | 80,0 | 100,0 | 50,0 |
| **Бюджеттан тыш акчалар** | | | | | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |